**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 8 октябрь № 752

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 10 декабрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 10 декабрь, 974 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 16 февраль, 93 нче; 2015 ел, 3 июнь, 402 нче; 2015 ел, 30 июнь, 473 нче; 2015 ел, 20 август, 609 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган торак булмаган фонд белән идарә итү һәм аны эксплуатацияләү буенча дәүләт эшләренә норматив чыгымнарның 4.7 нче пунктындагы икенче графада «музее» сүзен «музей-тыюлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарның 4.7 нче пунктындагы икенче графада «музее» сүзен «музей-тыюлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарда:

2.7 нче пунктның икенче графасында «музее» сүзен «музей-тыюлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

7 бүлекнең 7.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «7.1. | «Сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тер-нәкләндерү республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтү | 206,03<br>1 октябрьдән»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күләмнәре нормативларының 2.7 нче пунктындагы икенче графада «музее» сүзен «музей-тыюлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар, гамәле 2015 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган 1 нче пунктның алтынчы абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы                                                                  А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\752.docx